РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 55-0-43, факс 55-0-43

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**18 .01. 2021** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Зеленовка торак пунктында 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, “Татарстан Республиксында җирле үзидарәләр турында”гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Нармонка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә **КАРАР КЫЛАМ:**

1. 2021 елның 29 гыйнварында 9 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Зеленовка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча Зеленовка авылында гражданнар җыенын үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарылачак мәсьәләне раслау:

“Сез, 2021 елга түбәндәге эшләрне, ягъни:

- Авыл эчендәге юлларны ремонтлау эшләрен башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен Бөек Ватан сугышында катнашучыарның тол хатыннары, балачактан инвалид, күп балалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Зеленовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буларак теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан үзара салымга 1000 сум күләмендә акча җыелырга ризамы?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү йөкләнелә.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылган көненнән башлап үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Нармонка авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Т.А. Хәкимов**